ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 08 » ноябрь 2021 г.** **№ 35**

«Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021 ел, № 24 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021 ел, № 24 карары белән расланганагачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «авария хәлендәге агачлар, куаклар турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3.пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «яки гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, бик кирәк булганда (авария хәлендәге агачлар), яшел үсентеләрне юк итү зарурилыгы расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында. «(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки аеруча кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итүгә бәйле очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында. «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктны төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында. «;мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә бик кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентның 2 нче кушымтасында «авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Хамидуллин Р.В.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012741